# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕГЕ

# ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Казанский (Приволжский) федеральный университет
Институт филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого

# ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

СЛОВАРЬ

МОРФОЛОГО-ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ СПРАВОЧНИК

Около 46 000 слов

*Второе издание, дополненное*

КАЗАНЬ • ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • 2017

Казан (Идел буе) федераль университеты
Лев Толстой ис. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕГЕ

СҮЗЛЕК

МОРФОЛОГИК-
ОРФОГРАФИК
БЕЛЕШМӘЛЕК

Якынча 46 000 сүз

*Тулыландырылган икенче басма*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2017

УДК (038)811.512.145
ББК 81.2 Тат-4
Т23

Төзүчеләр:
*К. Р. Галиуллин, Р. И. Раскулова*

Фәнни мөхәррир
*Г. Р. Галиуллина*

Рецензентлар:
*А. Ф. Гайнетдинова, Р. Н. Кәримуллина*

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

Т23 **Татар теленең орфографик сүзлеге** : Сүзлек. Морфологик-орфографик белешмәлек = Орфографический словарь татарского языка : Словарь. Морфолого-орфографический справочник : Якынча 46 000 сүз / төз.: К. Р. Галиуллин, Р. И. Раскулова ; фәнни мөх. Г. Р. Галиуллина. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. – 423 б.
ISBN 978-5-298-03387-9

Укучылар, студентлар, укытучылар, нәшрият һәм газета-журнал редакциясе хезмәткәрләре өчен чыгарылган әлеге сүзлектә хәзерге татар теле лексикасының төрле катламнары туплап бирелә. Шулай ук исем һәм фигыль формаларының ясалышы һәм язылышы турында тулы мәгълүмат тупланган морфологик-орфографик белешмәлек тә тәкъдим ителә.

УДК (038)811.512.145
ББК 81.2 Тат-4

ISBN 978-5-298-03387-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2017
© Галиуллин К. Р., Раскулова Р. И., төзү, 2017

## Ⓣ 1. КЕРЕШ
## Ⓡ 1. ВВЕДЕНИЕ

### Ⓣ 1.1. Сүз башы
### Ⓡ 1.1. Предисловие

Сүзлектә хәзерге татар теле лексикасының төрле катламнары (тамыр сүзләр, ясалма сүзләр һәм кушма сүзләр, төп сүзләр һәм алынма сүзләр, гамәлдәге терминнар һәм башка берәмлекләр), шулай ук кулланыштагы сүз ясагыч элементлар (*авиа..., авто..., социал-* һ. б.) урын ала.

Сүзлеккә 46 000 чамасы сүз кергә һәм анда өч миллионлап исем (22 меңнән артыграк сүз) белән фигыль (9 меңнән артык сүз) формаларының ясалышы һәм язылышы турында мәгълүмат бирелә.

Сүзлек соңгы елларда кулланышка кергән лексик берәмлекләр исәбенә тулыландырылды.

Сүзлекне төзегәндә, бу өлкәдә эшләгән белгечләрнең тәҗрибәсе исәпкә алынды, моңа кадәр басылып чыккан тел белешмәлекләре һәм махсус хезмәтләр файдаланылды (файдаланылган төп әдәбият исемлеге 4.3 нче бүлектә).

Сүзлекнең икенче басмасын әзерләгәндә, 2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын үтәү кысаларында

В словаре представлены различные пласты лексики современного татарского языка (непроизводные, производные и сложные слова, исконные и заимствованные слова, наиболее употребительные термины и другие единицы), а также словообразовательные элементы (*авиа..., авто..., социал-* и др.).

Словарь включает около 46 000 слов и в нём даны сведения об образовании и написании около трёх миллионов форм существительных (более 22 тысяч слов) и глаголов (более 9 тысяч слов).

Словарь пополнен за счёт лексических единиц, получивших распространение в последние годы.

При составлении словаря учитывался опыт предшественников, использовались материалы вышедших языковых справочников и специальных публикаций (список основной использованной литературы даётся в разделе 4.3).

При подготовке второго издания словаря были использованы материалы электронного фонда словарей, создаваемого в рамках реализации Государственной программы Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию государственных языков Рес-

тупланучы сүзлекләрнең электрон фонды материаллары файдаланылды.

Әлбәттә, бүгенге көндә массакүләм мәгълүмат чараларында, басылып чыккан хезмәтләрдә, фәнни тикшеренүләрдә татар теленең орфографиясе проблемаларын хәл итүгә карашлар төрлелеге һәм шактый сүзләрнең язылышында вариантлылык яшәп килгәндә (карагыз, мәсәлән, *газета* / *газет* / *гәзит* / *гәҗитә* / *гәҗит* һ. б.), шулай ук беркадәр сүзләрнең телдә тоткан урынын аңлатуда төрлелек булганда (мәсәлән, бер үк берәмлекләрнең төрле сүзлекләрдәге грамматик характеристикасы), дөрес язу проблемаларын тулаем берьюлы гына хәл итү мөмкин түгел. (Әйтергә кирәк, аларның күпчелеге алынма сүзләргә карый.)

Орфография проблемаларының шактый өлеше хәзерге алфавитка, анда татар теленең үзенчәлекле авазларын, мәсәлән [қ], [ғ], [w] авазларын, белдерү өчен махсус хәрефләр булмауга бәйле (бу хакта җентекләбрәк [Абдуллина, 2006]).

Тел берәмлекләренә төрлечә карашларның яшәп килүе сүзлектә сүзләрне системалап бирүне һәм аларны тасвирлауда бердәйлек булдыруны бик нык чикли.

Татар теленең тулы, системалаштырылган сүзлеген булдыру – гаять мөһим һәм катлаулы мәсьәлә, һәм ул ачык тикшерүгә теоретик һәм практик белгечләрнең киң катлавы җәлеп ителеп, шулай ук төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларны (алар арасында төрле сүзлекләр һәм татар теленең электрон корпуслары аерым урын тота; карагыз, мәсәлән, http://corpus.tatar) исәпкә алып хәл ителергә тиеш.

публики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 годы.

Конечно, в настоящее время, когда в печатных средствах массовой информации, в публикациях, научных исследованиях представлены различные подходы к решению орфографических проблем татарского языка, когда наблюдается вариативность в написании значительного количества слов (см., например, *газета* / *газет* / *гәзит* / *гәҗитә* / *гәҗит* и др.), а также различие в интерпретации языкового статуса ряда слов (например, грамматические характеристики одних и тех же единиц в разных словарях) трудно сразу решить все проблемы правописания (кстати, многие из них связаны с написанием заимствованных слов).

Значительная часть орфографических трудностей обусловлена составом современного алфавита, связана с отсутствием в нём специальных букв для обозначения специфических звуков татарского языка; например, звуков [қ], [ғ], [w] (подробнее об этом [Абдуллина, 2006]).

Имеющееся различие в подходах к языковым единицам существенно затрудняет системное представление слов в словаре и единообразное их описание.

Создание полного, системного орфографического свода татарского языка – чрезвычайно важная и сложная задача, и она должна решаться в процессе открытого обсуждения с участием широкого круга специалистов (как теоретиков, так и практиков), а также с учётом данных различных источников, среди которых особое место занимают материалы словарей различного типа и электронных корпусов татарского языка (см., например: http://corpus.tatar).

Хәзерге көндә Дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Казан федераль университетының Лев Толстой ис. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының тел белгечләре коллективы тарафыннан татар теленең электрон компонентлы академик грамматик-орфографик сүзлеге эшләнә. Төзүчеләр татар орфографиясенең һәм аның сүзлектәге тасвирламасының хәл ителмәгән күп кенә мәсьәләләрен киң катлау галимнәр катнашында хәл итеп булыр һәм аның нәтиҗәләре әлеге академик белешмәлек кысаларында чагылыш табар дип өметләнәләр.

Халыкара элемтәләр киңәю һәм ныгуга, төрле милләт халыкларының Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең берсе булган татар теле белән кызыксынуы артуга бәйле рәвештә, сүзлекне төзүчеләр башка телләрдә сөйләшүче татарстанлыларның, Россия төбәкләрендә һәм чит дәүләтләрдә яшәүчеләрнең татар телен өйрәнүгә ихтыяҗларын исәпкә алырга тырыштылар.

Татар орфографиясендәге катлаулы мәсьәләләрнең хәл ителеп бетмәгәнлеген аңлаган хәлдә, авторлар тулы, системалы орфографик тупланма төзергә ярдәм итәрдәй теләк-тәкъдимнәргә рәхмәтле булачак.

Төзүчеләр әлеге сүзлек материалларын тикшерүдә катнашкан белгечләргә һәм Татарстан китап нәшриятының барлык хезмәткәрләренә рәхмәт белдерәләр.

В настоящее время в рамках названной выше Государственной программы коллективом лингвистов Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан и Института филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого Казанского федерального университета разрабатывается академический грамматико-орфографический словарь татарского языка (с электронным компонентом). Составители этого словаря надеются, что многие проблемные вопросы татарского правописания и его словарного описания удастся решить в ходе широкого обсуждения и его результаты найдут отражение в рамках академического справочника.

В связи с расширением и усилением международных связей, с возрастанием интереса к татарскому языку, одному из двух государственных языков Республики Татарстан, составители стремились учесть также потребности в изучении татарского языка иноязычных татарстанцев, жителей других регионов Российской Федерации и граждан зарубежных государств.

Осознавая, что ещё не все сложные вопросы правописания слов в татарском языке решены, авторы с благодарностью примут пожелания, которые будут способствовать созданию полного, системного орфографического свода.

Составители выражают благодарность специалистам, принимавшим участие в обсуждении данного словаря, и всем сотрудникам Татарского книжного издательства.

## Ⓣ 1.2. Сүзлекнең төзелеше
## Ⓡ 1.2. Структура словаря

Китап керештән (⇨ 1), сүзлек (⇨ 2), морфологик-орфографик белешмәлек (⇨ 3) һәм кушымтадан (⇨ 4) тора.

**А.** Керешкә түбәндәге бүлекләр керә:

**А.1.** Сүз башы (⇨ 1.1). Бу өлештә сүзлеккә гомуми характеристика бирелә.

**А.2.** Сүзлекнең төзелеше (⇨ 1.2). Биредә сүзлекнең бүлекләре һәм бүлекчәләре тасвирлана.

**А.3.** Сүзлектәге сүзләрнең тасвирламасы (⇨ 1.3). Орфографик сүзлектәге сүзләрнең бирелү принциплары тасвирлана.

**А.4.** Сүзлектә файдаланылган шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар (⇨ 1.4). Бу өлештә кыскартылмаларга аңлатма бирелә һәм шартлы билгеләр белдергән мәгълүмат күрсәтелә.

**А.5.** Алфавит. Биредә татар алфавиты һәм, беренче хәрефләренә карап, сүзләрнең урнашу тәртибе – сүзлектәге бит номерлары китерелә.

**В.** Төп өлешне ике белешмә компонент тәшкил итә.

**В.1.** Татар әдәби телендәге уртаклык исемнәрнең орфографик сүзлеге (⇨ 2). Сүзләрнең бирелү

Книга состоит из введения (⇨ 1), словарной части (⇨ 2), морфолого-орфографического справочника (⇨ 3) и приложения (⇨ 4).

**А.** Введение включает следующие разделы:

**А.1.** Предисловие (⇨ 1.1) Здесь дана общая характеристика словаря.

**А.2.** Структура словаря (⇨ 1.2). Здесь описаны разделы и подразделы словаря.

**А.3.** Описание слов в словаре (⇨ 1.3). Здесь изложены принципы подачи слов в орфографическом словаре.

**А.4.** Условные обозначения и сокращения, использованные в словаре (⇨ 1.4). Здесь расшифрованы сокращения и указана информация, о которой сообщают условные обозначения.

**А.5.** Алфавит. Здесь приведён татарский алфавит с номерами страниц словаря, на которых расположены слова с соответствующей начальной буквой.

**В.** Основную часть составляют два справочных компонента.

**В.1.** Орфографический словарь, включающий нарицательную лексику татарского литературного

принциплары турында тулырак мәгълүмат (⇨ 1.3).

**В.2.** Морфологик-орфографик белешмәлек (⇨ 3). Биредә исем һәм фигыльнең төп формаларының ясалышы һәм язылышы турында мәгълүматлар китерелә. Белешмәлекнең төзелеше турында 357–358 нче битләрне карагыз.

**С.** Кушымтага (⇨ 4) түбәндәге бүлекләр керә:

**С.1.** Форма ясагыч кушымчалар (⇨ 4.1). Биредә, белешмәлекнең (⇨3) тиешле формалар тасвирланган бүлекчәләрен дә күрсәтеп, исем һәм фигыльнең төп формаларын ясаучы кушымчаларның алфавит тәртибендәге исемлеге китерелә.

Индекслары күрсәтелгән бүлекләр исемлеген I (исем, 359 нчы б.) һәм II (фигыль, 369–371 нче б.) бүлек башларында карагыз.

Әлеге материаллар форма ясауда нинди кушымчалар катнашуы һәм әлеге кушымчалар ярдәмендә исем һәм фигыльләрнең нинди формалары ясалуы турында мәгълүмат бирә.

**С.2.** Сүз ясагыч кушымчалар (⇨ 4.2). Биредә: a) исемнәр (продуктив төрләрне карагыз [ТГ(т), 1: 244–262]) һәм b) фигыльләр (продуктив төрләрне карагыз [ТГ(т),1: 326–346]) ясаучы кушымчаларның инверсион исемлекләре китерелә.

Кушымчалар морфологик-орфографик белешмәлектәге (⇨ 3) 3.I.0 (исем, 360–362 нче б.) һәм 3.II.0 (фигыль, 372–373 нче б.) номерлы таблицаларда тасвирланган үзгәреш төрләренә сылтамалар белән бирелә.

Билгеле булганча, хәзерге та-

языка (⇨ 2). Подробнее о принципах подачи слов (⇨ 1.3).

**В.2.** Морфолого-орфографический справочник (⇨ 3). Здесь представлены сведения об образовании и написании основных форм имён существительных и глаголов. О построении справочника см. с. 357–358.

**С.** Приложение (⇨ 4) включает следующие разделы:

**С.1.** Формообразующие аффиксы (⇨ 4.1). Здесь приведены алфавитные перечни аффиксов, образующих основные формы имени существительного и глагола, с указанием подразделов справочника (⇨ 3), где описаны соответствующие формы.

Перечень разделов с указанием их индексов см. в начале разделов I (имя существительное, с. 359) и II (глагол, с. 369–371).

Эти материалы дают сведения о том, какие аффиксы участвуют в образовании форм и какие формы существительного и глагола с помощью указанных аффиксов образуются.

**С.2.** Словообразующие аффиксы (⇨ 4.2). Здесь приведены инверсионные алфавитные перечни аффиксов, образующих: a) имена существительные (см. продуктивные типы в [ТГ(р), 1: 240–266]) и b) глаголы (см. продуктивные типы в [ТГ(р), 1: 412–442]).

Аффиксы сопровождаются ссылками на типы изменений, которые описаны в таблицах № 3.I.0 (имя существительное, с. 360–362) и № 3.II.0 (глагол, с. 372–373) морфолого-орфографического справочника (⇨ 3).

Как известно, в современном

тар телендә яңа исемнәрнең һәм аеруча фигыльләрнең күпчелек өлеше төрле кушымчалар ярдәмендә ясала. Югарыда күрсәтелгән материаллар теге яисә бу кушымчалы сүз формаларының ничек ясалуы һәм язылуы турында мәгълүмат бирә, бу исә хәтта әлеге сүзлеккә кермәгән сүз формаларының да (мәсәлән, яңа сүзләрнең) ясалуы турында мәгълүмат алырга мөмкинлек тудыра.

**С.3.** Әдәбият (⇨ 4.3). Биредә әлеге сүзлекне төзегәндә файдаланылган төп сүзлекләр, шулай ук белешмәлекләр һәм махсус басмалар күрсәтелә.

татарском языке значительная часть новых имён существительных и особенно глаголов создаётся различными аффиксальными способами. Указанные выше материалы дают сведения о том, как образуются и пишутся формы у слов с тем или иным аффиксом, что позволяет получить информацию об образовании форм даже тех слов, которые не отражены в данном словаре (например, новых слов).

**С.3.** Литература (⇨ 4.3). Здесь указаны основные словари, справочники и специальные издания, использованные при составлении данного словаря.

## Ⓣ 1.3. Сүзлектәге сүзләрнең тасвирламасы
## Ⓡ 1.3. Описание слов в словаре

Сүзлектәге сүзләр татар алфавиты тәртибендә урнаша (алфавитны 18 нче биттән карагыз).

Сүзлектә хәзерге татар телендәге уртаклык исемнәр тасвирлана. Тасвирлау берәмлекләре – сүзләр; тезмә сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр һәм фразеологик берәмлекләр сүзлеккә керми.

Кайбер очракларда, сүзнең мәгънәсен, кулланылыш үзенчәлекләрен аңлату өчен, түгәрәк җәяләр эчендә гадәти шрифт белән сүзтезмәләрнең компонентлары бирелә; мәсәлән:

Слова в словаре располагаются в соответствии с татарским алфавитом (см. алфавит на с. 18).

В словаре описывается нарицательная лексика современного татарского языка. Единицы описания – слова; не включаются составные слова, устойчивые сочетания, фразеологизмы.

В ряде случаев для пояснения значения слова, особенностей его употребления приводятся в круглых скобках прямым шрифтом компоненты словосочетаний; например:

агар (~су)
аза́р-бизәр (~китерү)

Омонимнар татар теле материалларын тасвирлаган төп сүзлекләрдәге мәгълүматларга нигезләнеп күрсәтелә. Алар рим цифрлары белән билгеләнә, моннан тыш, кыскартылмалар ярдәмендә сүз төркеме күрсәтелә. Бер сүз төркемендәге бертөрле үзгәрешле сүзләр бер мәкаләдә бирелә; мәсәлән:

Омонимы выделяются на базе данных основных словарей татарского языка. Они обозначаются римскими цифрами, кроме того, с помощью сокращений указывается часть речи. Одинаково изменяющиеся слова одной части речи приводятся в одной статье; например:

ат, -ы I–II (*ис.*)
кун|у, -уы (**кунарга) I–II (*фг.*)

Төрле сүз төркемнәренә караган омонимнар һәм төрлечә үзгәрә торган исемнәр һәм фигыльләр төрле сүзлек мәкаләләрендә китерелә; мәсәлән:

Омонимы, относящиеся к разным частям речи, и по-разному изменяющиеся существительные и глаголы приводятся в разных словарных статьях; например:

тә I (*кис.*)
тә II (*терк.*)
ию, -е (*и, **ияргә) I (*фг.*)
ию, -е (*йе, **иергә) II (*фг.*)

Сүзлектә баш берәмлекләрдә сүзләрнең басымнары күрсәтелә, ләкин, татар теленең күпчелек сүзләренә хас булганча, соңгы иҗеккә төшсә, басым күрсәтелми; мәсәлән:

В словаре указывается ударение в заголовочных словах, при этом ударение не отмечается, когда оно падает на последний слог (как в большинстве слов татарского языка); например:

компью́тер, -ы
егәрле|к, -ге

Сызыкча аша язылa торган сүзләрдә, парлы сүзләрдә басым билгесе сүзнең ике өлешендә дә куела (икенчесендә – басым соңгы иҗеккә төшмәсә) мәсәлән:

В словах с дефисным написанием, в парных словах знак ударения ставится в обеих частях слова (во второй – если ударение падает не на последний слог); например:

авы́з-борын, авызы́-борыны
милли́-патрио́тик

Басым вариантлары күрсәтелә; мәсәлән:

Отмечаются варианты ударения; например:

ма́ркéтинг, -ы
металлу́ргия́, -се

Сүзлектә төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр урын ала һәм алар башлангыч формада бирелә (исем – баш килештә, берлек санда, фигыль – *-у(-ю) / -ү(-ю)* кушымчалы исем фигыль рәвешендә); мәсәлән:

В словаре представлены слова разных частей речи, которые приводятся в начальных формах (имена – в форме именительного падежа единственного числа, глагол – в форме имени действия на *-у(-ю) / -ү(-ю)*); например:

авыл, -ы
каптыр|у, -уы I–II (*фг.*)

Исемнәр һәм фигыльләр өчен әлеге сүзләрнең төрле формаларының ясалыш һәм язылыш үзенчәлекләре турында мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә торган материаллар китерелә:

1) исемнәрнең – 3 нче зат тартымлы формасы; бу очракта башлангыч форманың үзгәрми торган өлеше үзгәрә торганыннан вер-

Для имён существительных и глаголов приводятся материалы, позволяющие получить сведения об особенностях образования и написания различных форм этих слов:

1) для имён существительных – форма принадлежности 3 лица; при этом неизменяемая часть начальной формы слова отделяется

тикаль сызык белән аерыла; мәсәлән:

от изменяемой с помощью вертикальной черты; например:

абага, -сы
түшә|к, -ге

Тартымлы форма *-е* ярдәмендә бирелсә, сүзләрнең калын нигезле икәнен күрсәтү өчен, юнәлеш килеше кушымчасы да китерелә; мәсәлән:

Если форма принадлежности передаётся с помощью *-е,* то для обозначения слов с твёрдой основой приводится также окончание направительного падежа; например:

мала|й, -е(на)
киңәш, -е

2) фигыльләрнең:

а) фигыль нигезе (ул 2 нче зат берлек сандагы боерык фигыльгә аваздаш була һәм сүзлектә, гадәттә, вертикаль сызык белән аерыла); мәсәлән:

2) для глаголов:

а) основа глагола (она представлена формой повелительного наклонения 2 лица единственного числа и обычно отделяется вертикальной чертой); например:

йөгер|ү, -үе I–III (*фг.*)
кайт|у, -уы (**кайтырга)

Фигыль нигезе сүзнең үзгәрми торган өлеше белән тәңгәл килмәгән очракта, әлеге форма түгәрәк җәяләр эчендә бер йолдызчыктан соң китерелә; мәсәлән:

В тех случаях, когда основа глагола не совпадает с неизменяемой частью слова, эта форма приводится в круглых скобках после звёздочки; например:

авыраю, -ы (*а́вырай)
ару, -ы (*а́ры) II (*фг.*)

b) исем фигыльнең 3 нче зат тартымлы формасы; мәсәлән:

b) форма принадлежности 3 лица имени действия; например:

кара|у, -вы I (*фг.*)
сал|у, -уы (**салырга) I–II (*фг.*)

Инфинитив формасының ясалышында кыенлыклар булганда (кагыйдә буларак, бу нигезе бер иҗекле фигыльләрдә күзәтелә), әлеге форма ике йолдызчыктан соң түгәрәк җәяләр эчендә китерелә; мәсәлән:

Когда возможны затруднения в образовании формы инфинитива (как правило, это наблюдается у глаголов с односложной основой), форма инфинитива приводится в круглых скобках после двух звёздочек; например:

авы, -ы (*ау, **аварга)
кит|ү, -үе (**китәргә) I–II (*фг.*)

Әлеге формалар үрнәк буларак китерелә. Алар нигезендә күпчелек очракта исем һәм фигыльләрнең башка формаларын да ясап була, моның өчен китаптагы морфологик-орфографик белешмәлектән файдаланырга тәкъдим ителә.

Кабатлау юлы белән ясала торган сүзләр өчен ике компонентлы берәмлекләр генә бирелә (*чут-чут-чут,пес-пес-пес* кебек өч һәм аннан да күбрәк компонентлы берәмлекләр сүзлеккә кертелми).

Сүз ясагыч элементлар кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәтә торган билгеләр белән бирелә: күп нокталар (...) – элементның күпчелек очракта кушылып язылуын, ә дефис (-) сызыкча аша язылуын күрсәтә; мәсәлән:

Данные формы являются показательными. По ним в большинстве случаев можно восстановить остальные формы имён существительных и глаголов, для чего рекомендуется пользоваться приведённым в книге морфолого-орфографическим справочником.

Для слов, образующихся повтором, приводятся только двухкомпонентные единицы (трёх- и более компонентные единицы типа *чут-чут-чут,пес-пес-пес* в словарь не включаются).

Словообразовательные элементы сопровождаются знаками, указывающими на особенности их употребления: многоточие (...) указывает на преимущественно слитное написание, а чёрточка (-) на дефисное написание; например:

ви́це-
радио...

## Ⓣ 1.4. Сүзлектә кулланылган шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар
## Ⓡ 1.4. Условные обозначения и сокращения, использованные в словаре

/ **авыш сызык** аера:
a) сүз (⇨ 2) вариантларын,
b) морфологик-орфографик белешмәлектәге (⇨ 3) татарча һәм русча материалларны,
c) кушымча вариантларын (⇨ 3)

| **вертикаль сызык** исемнең башлангыч формасының үзгәрә торган өлешен – үзгәрми торганыннан, кушымчаны фигыльнең нигезеннән аера (⇨ 2; 3)

( ) **түгәрәк җәяләр эчендә** аңлатмалар, сүзнең ахыргы хәрефләре (авазлары), сүз формалары (⇨ 2, 3) күрсәтелә

[ ] **квадрат җәяләр эчендә бирелә**:
a) әйтелеш турында мәгълүматлар (транскрипция) (⇨ 3),
b) сүзләрнең факультатив өлеше (⇨ 3),
c) файдаланылган әдәбиятка сылтамалар

* **йолдызчык** фигыль нигезе алдыннан куела (⇨ 2)

** **ике йолдызчык** фигыльнең инфинитив формасы алдыннан куела (⇨ 2)

<!> **почмаклы җәяләр эчендә өндәү билгесе** сүз формаларының ясалыш һәм язылыш үзен-

/ **косая черта** разделяет:
a) варианты слов (⇨ 2),
b) материалы татарского и русского языков в морфолого-орфографическом справочнике (⇨ 3),
c) варианты аффиксов (⇨ 3)

| **вертикальная линия** отделяет изменяемую часть начальной формы существительного от неизменяемой, а также аффикс от основы глагола (⇨ 2; 3)

( ) **в круглых скобках** приводятся пояснения, конечные буквы (звуки) слов, формы слов (⇨ 2, 3)

[ ] **в квадратных скобках** приводятся:
a) сведения о произношении (транскрипция) (⇨ 3),
b) факультативные части слов (⇨ 3),
c) ссылки на использованную литературу

* **звёздочка** ставится перед основой глагола (⇨ 2)

** **две звёздочки** ставятся перед неопределённой формой глагола (⇨ 2)

<!> **восклицательный знак в угловых скобках** ставится перед материалами, указывающими

чәлекләренә күрсәткән материаллар алдына куела (⇨ 3)

<1> **почмаклы җәяләр эчендә 1 саны** бер иҗекле сүзләргә (нигезгә) күрсәтә (⇨ 3)

<2...> **почмаклы җәяләр эчендә күп нокталы 2 саны** ике яисә аннан да артыграк иҗекле сүзләргә (нигезгә) күрсәтә (⇨3)

≠ **тигезсезлек билгесе** «...дан башка» мәгънәсендә кулланыла (⇨ 3)

∅ **«сызылган нуль» тамгасы** сүз формасында хәрефнең юклыгын күрсәтә (⇨ 3)

■ **кара квадрат** белән калын нигезле сүзләргә караган материаллар билгеләнә (⇨ 3)

□ **ак квадрат** белән нечкә нигезле сүзләргә караган материаллар билгеләнә (⇨ 3)

...м **күп нокта белән хәрефләр** шул хәрефләргә (авазларга) тәмамланган сүзләрне күрсәтә (⇨ 3)

...Суз. **күп нокта белән кыскарту** (Суз., Тарт., Саңг., Яңг.) тиешле хәрефләргә (авазларга) тәмамланган сүзләрне белдерә (⇨ 3)

<u>я</u> **астына сызылган хәреф** сүз формалары ясагандагы үзгәрешләр турында кисәтә (⇨ 3)

⇨ **уңга караган калын ак ук** әлеге сүзлекнең тиешле бүлекләренә һәм бүлекчәләренә җибәрә

~ **дулкынлы сызык** сүзнең төрле формаларында үзгәрә торган хәрефләр (авазлар) арасында куела (⇨ 3)

ˆ **«түбә» тамгасы** тартыкның саңгыраулыгын яисә саңгырау кебек кулланылуын күрсәтә (⇨3; 3.I.0, 3.II.0 нче таблицалар)

на особенности образования и написания форм слов (⇨ 3)

<1> **цифра 1 в угловых скобках** обозначает слова (основы), состоящие из одного слога (⇨ 3)

<2...> **цифра 2 с многоточием в угловых скобках** обозначает слова (основы), состоящие из двух и более слогов (⇨ 3)

≠ **знак неравенства** используется в значении «кроме» (⇨ 3)

∅ **знак «перечёркнутый нуль»** обозначает отсутствие буквы в форме слова (⇨ 3)

■ **чёрным квадратом** отмечаются материалы слов с твёрдой основой (⇨ 3)

□ **белым квадратом** отмечаются материалы слов с мягкой основой (⇨ 3)

...м **многоточие и буквы** обозначают слова, заканчивающиеся на соответствующие буквы (звуки) (⇨ 3)

...Гл. **многоточие и сокращение** (Гл., Согл., Глух., Звон.) обозначают слова, которые заканчиваются на соответствующие буквы (звуки) (⇨ 3)

<u>я</u> **подчёркнутая буква** предупреждает об изменениях при образовании форм слова (⇨ 3)

⇨ **широкая светлая стрелка вправо** отсылает к соответствующим разделам и подразделам данного словаря

~ **волнистая линия** ставится между буквами (звуками), меняющимися в разных формах слова (⇨ 3)

ˆ **знак «крышечка»** указывает на то, что согласный является глухим или употребляется как глухой (⇨ 3; таблицы № 3.I.0, 3.II.0)

\+ **кушу билгесе** нинди дә булса элемент кушылуны, өстәлүне күрсәтә (⇨ 3)

Ⓟ **«Р» хәрефле түгәрәк** русча язылган бүлек исеме һәм рус телендәге материаллар алдыннан куела

Ⓣ **«Т» хәрефле түгәрәк** татарча язылган бүлек исеме һәм татар телендәге материаллар алдыннан куела

1,1 ... 4.3 – **гарәп цифрлары** сүзлекнең бүлек һәм бүлекчә номерларын күрсәтә

3.I.A ... 3.II.J – **латин хәрефләре белән рим цифрлары (еш кына гарәп цифрлары да)** белешмәлекнең (⇨ 3) бүлек һәм бүлекчә номерларын күрсәтә (атамалары белән барлык бүлек һәм бүлекчәләр исемлеге ⇨ 3; 3.I һәм 3.II нче бүлекләр башында)

*Курсив* белән кушымчалар, сүзләрнең ахыргы хәрефләре (авазлары) бирелә (⇨ 3)

\+ **знак сложения** указывает на присоединение, добавление какого-либо элемента (⇨ 3)

Ⓟ **кружочек с буквой «Р»** ставится перед заголовком и материалами на русском языке

Ⓣ **кружочек с буквой «Т»** ставится перед заголовком и материалами на татарском языке

1,1 ... 4.3 – **арабские цифры** указывают на номера разделов и подразделов словаря

3.I.A... 3.II.J – **римские цифры с латинскими буквами (нередко и с арабскими цифрами)** указывают на номера разделов и подразделов справочника (⇨ 3) (перечень всех разделов и подразделов с названиями ⇨ 3; в начале разделов 3.I и 3.II)

*Курсивом* даны аффиксы, а также конечные буквы (звуки) слов (⇨ 3)

| | |
|---|---|
| б. | Ⓣ бит(ләр) Ⓟ страница(ы) |
| Б.к. | Ⓣ баш килеш Ⓟ основной падеж |
| бер. | Ⓣ берлек (сан) Ⓟ единственное (число) |
| В.п. | Ⓟ винительный падеж Ⓣ төшем килеше |
| Гл. | Ⓟ гласный Ⓣ сузык |
| Глух. | Ⓟ глухой согласный Ⓣ саңгырау тартык |
| ед. | Ⓟ единственное (число) Ⓣ берлек (сан) |
| Звон. | Ⓟ звонкий согласный Ⓣ яңгырау тартык |
| И.к. | Ⓣ иялек килеше Ⓟ притяжательный падеж |
| И.п. | Ⓟ исходный падеж Ⓣ чыгыш килеше |
| ис. | Ⓣ исемендәге Ⓟ имени |
| к. | Ⓣ килеш Ⓟ падеж |
| кара. | Ⓣ карагыз Ⓟ смотрите |
| күп. | Ⓣ күплек (сан) Ⓟ множественное (число) |
| М.-в.п. | Ⓟ местно-временной падеж Ⓣ урын-вакыт килеше |

| | |
|---|---|
| мн. | Ⓡ множественное (число) Ⓣ күплек (сан) |
| Н. п. | Ⓡ направительный падеж Ⓣ юнәлеш килеше |
| О. п. | Ⓡ основной падеж Ⓣ баш килеш |
| п. | Ⓡ падеж Ⓣ килеш |
| П. п. | Ⓡ притяжательный падеж Ⓣ иялек килеше |
| С. | Ⓡ страница(-ы) Ⓣ бит(ләр) |
| Саңг. | Ⓣ саңгырау тартык Ⓡ глухой согласный |
| см. | Ⓡ смотрите Ⓣ карагыз |
| Согл. | Ⓡ согласный Ⓣ тартык |
| Суз. | Ⓣ сузык Ⓡ гласный |
| Тарт. | Ⓣ тартык Ⓡ согласный |
| Т. к. | Ⓣ төшем килеше Ⓡ винительный падеж |
| У.-в. к. | Ⓣ урын-вакыт килеше Ⓡ местно-временной падеж |
| Форз. 1 | Ⓣ беренче (китап башындагы) форзац Ⓡ первый форзац (в начале книги) |
| Форз. 2 | Ⓣ икенче (китап ахырындагы) форзац Ⓡ второй форзац (в конце книги) |
| Ч. к. | Ⓣ чыгыш килеше Ⓡ исходный падеж |
| Ю. к. | Ⓣ юнәлеш килеше Ⓡ направительный падеж |
| Яңг. | Ⓣ яңгырау тартык Ⓡ звонкий согласный |

## Алфавит

| Ⓣ Хәреф Ⓡ Буква | Ⓣ Битләр Ⓡ Страницы | Ⓣ Хәреф Ⓡ Буква | Ⓣ Битләр Ⓡ Страницы | Ⓣ Хәреф Ⓡ Буква | Ⓣ Битләр Ⓡ Страницы |
|---|---|---|---|---|---|
| А а | 19–39 | К к | 117–169 | Ф ф | 302–310 |
| Ә ә | 39–43 | Л л | 169–176 | Х х | 310–315 |
